РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь 2023 ел Буа шәһәре № 8-56

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 3-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 декабрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 3-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 нче кушымтасын 1 нче кушымта буенча үзгәртеп һәм киләсе редакциядә язып куярга.

2. Әлеге карарны Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башлыгы вазыйфаларын
башкаручы, Совет рәисе урынбасары И.Ф.Еремеев

ТР Буа муниципаль районы Советының
2023 елның 15 декабрендәге 8-56 номерлы карарына
1 нче кушымта

« ТР Буа муниципаль районы Советының
2021 елның 22 ноябрендәге 1-21 номерлы карарына
3 нче кушымта

## Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм торак пункт чикләрендә юл хуҗалыгында һәм (яисә) бер үк җирле әһәмияттәге юлда юл хуҗалыгында муниципаль контроль объектында утыз календарь көн дәвамында ике һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәте.

2. Автомобиль транспортында, шәһәр, җир өсте, электр транспортында, йөртүчеләр тарафыннан кылынган, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрен бозу фактларын бер календарь ел дәвамында, алдагы календарь ел белән чагыштырганда, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматлар нигезендә биш процентка һәм аннан күбрәк бозу фактларына арттыру.

3. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматларга нигезләнеп, бер календарь ел дәвамында юл инфраструктурасы объектында юл-транспорт һәлакәтләре санын ике тапкырга һәм аннан да күбрәк тапкырга арттыру.

4. Контрольдә тотылучы затны билгән яисә файдаланган юл участогында юл-транспорт һәлакәтләренең календарь аена кимендә биш процентка арту, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда.

5. Хисап елы дәвамында юлның бер участогында, яки юл һәм урамнар киселешендә, кешеләр зыян күргән яки яраланган канәгатьләнерлек булмаган юл шартларына бәйле рәвештә, бер төрдәге юл-транспорт һәлакәте килеп чыгу фактлары ачыклану.